СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

24.11.2020 Әгерҗе ш. № 3-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Документларны имзалау һәм муниципаль норматив хокукый актлар кабул итү турында» 01.09.2020 № 21-53-10-2318 хатын исәпкә алып, муниципаль районнарга җирлекләр тарафыннан аерым бюджет вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актлар кабул итү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында беркетелгән килешүләр төзү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә..

Совет рәисе урынбасары,
Муниципаль берәмлек
башлыгы урынбасары И.Э.Шәймөхәмәтов

Расланган
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карары белән
2020 елның 24 ноябрендәге № 3-3

Тәртип
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе (алга таба - Район) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнгән.

2. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Районның җирле үзидарә органнары белән килешү төзиләр.

Шул ук вакытта Районның җирле үзидарә органнары «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, район җирле үзидарә органнарына «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләр бирү турындагы килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең һәм (яисә) Район муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тапшыра.

4. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты үз инициативасы белән, йә районның җирле үзидарә органнары инициативасын карап, аны алган көннән алып 30 көн эчендә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне бирү турындагы карары проектын әзерли.

5. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советына норматив хокукый актлар керткәндә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карары проектын кертә.

6. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы район җирле үзидарә органнарына «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны Районның җирле үзидарә органнарына карауга җибәрә.

7. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карарын уңай карау нәтиҗәсендә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Районның җирле үзидарә органнары арасында килешү төзелә.

Күрсәтелгән килешү билгеле бер срокка төзелә, аның гамәлдә булуын туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләр, шул исәптән вакытыннан алда, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның әлеге өлештә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибе, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләре бирүне күздә тота.

Килешү проектын эшләү өчен, һәр яктан бертигез санда вәкилләр кертелеп, эш төркеме төзелә. Эш төркеме үз эше нәтиҗәләре буенча килешү проектын әзерли, ул килешү якларының мәнфәгатьләрен максималь исәпкә ала.

8. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы район җирле үзидарә органнарына «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы карар проектын кире каккан очракта, алар инициативасы белән чыккан мәсьәләне карау нәтиҗәләре турында хат җибәрелә.

9. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм район бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә, анда тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга акчалар карала.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә йә бер үк вакытта барлык финанс чараларының суммасын күчерү.

10. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен муниципаль мөлкәт түләүсез вакытлы файдалану шартнамәсе нигезендә тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе ашыгыч рәвештә һәм Килешүнең гамәлдә булу срогына төзелә.

11. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Районның җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.

12. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләрен тапшырган җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында мәгълүмат соратып ала.

13. Килешүнең гамәле вакытыннан алда туктатыла:

- яклар килешүе буенча;

- берьяклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

14. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Район җирле үзидарә органы файдаланылмаган финанс чараларын һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.

15. Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.